**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**ДҮРТ-МУНЧА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАРЫ

**№ 124** **21.09.2018 ел**

**«Гражданнарның үзара салымы турында» 2014 елның 05 февралендәге 130 номерлы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Гражданнарның үзара салымы турында» 2014 елның 05 февралендәге 130 номерлы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Советы карары белән расланган Дүрт-Мунча авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. II бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 6 пунктны өстәргә:
«6. Гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе авыл җирлеге башкарма комитеты кабул иткән муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.»;
1.2. III бүлекне төшереп калдырырга.
2. Карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Р.Т.Ситдыйков**